СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2022 г.Зеленодольск № 175

Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү турындагы нигезләмәне раслау хакында

2003 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү турындагы нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы карарына карата кушымта
2022 елның 20 маендагы 175
номерлы карары

# Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге Нигезләмә нигезендә Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында (алга таба – җирле үзидарә органы) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү тәртибе билгеләнә.

1.2. Аттестация муниципаль хезмәткәрнең биләгән вазыйфасына туры килүен билгеләү максатларында, аның һөнәри эшчәнлеген бәяләү нигезендә үткәрелә.

Аттестация муниципаль хезмәтнең кадрлар составын формалаштыруга, муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрүгә, җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын кыскартканда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә өстенлекле хокукны билгеләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартларын үзгәртүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән.

1.3. Түбәндәге муниципаль хезмәткәрләр аттестация үтәргә тиеш түгел:

а) муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасында бер елдан ким эшләгән затлар;

б) 60 яшькә җиткәннәр;

в) йөкле хатын-кызлар;

г) йөклелек һәм бала табу буенча отпускта яисә бала карау буенча отпускта булган затлар - балаларына өч яшь тулганчы. Әлеге муниципаль хезмәткәрләрне отпусктан чыкканнан соң бер елдан да иртәрәк аттестацияләү мөмкин түгел;

д) сроклы хезмәт килешүе (контракт) нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар.

1.4. Аттестация барышында муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлегенә түбәндәге характеристикалардан чыгып бәя бирелә:

муниципаль хезмәткәрнең тиешле бүлекчә (җирле үзидарә органы) алдында торган йөкләмәләрне тормышка ашыруга юнәлдерелгән мәсьәләләрне (документларны) хәл итүдә (эшләүдә)катнашуы;

муниципаль хезмәткәр башкара торган һөнәри хезмәт эшчәнлегенең катлаулылыгы, аның эффективлыгы һәм нәтиҗәлелеге;

вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәк булган квалификация таләпләренә, муниципаль хезмәт стажына яки белгечлегенә, әзерлек юнәлешенә, белемнәргә һәм күнекмәләргә шулай ук эшкә алучы вәкиленең тиешле карары

булган очракта - белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча туры килү-килмәве;

муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт дисциплинасын һәм чикләүләрне үтәмәү, тыюларны бозу, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән йөкләмәләрне үтәмәү фактлары булмавы.

1.5. Аттестацияне оештыруны һәм үткәрүне, Зеленодольск муниципаль районының бердәм аттестация комиссиясе (алга таба - Комиссия) турында нигезләмәдә каралган тәртиптә, Зеленодольск муниципаль районының бердәм аттестация комиссиясе гамәлгә ашыра.

Комиссиянең персональ составы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карары белән төзелә.

1.6. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү өч елга бер тапкыр үткәрелә.

## 2.Аттестация үткәрүне оештыру

2.1. Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү өчен район Башлыгы түбәндәге нигезләмәләрдән торган карар чыгарыла:

1) аттестация үткәрү графигын һәм аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәрләр исемлеген раслау турында, шулай ук һәр аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрнең әлеге документлары белән танышуны оештыру хакында

2) турыдан – туры җитәкче тарафыннан аттестация чорында муниципаль хезмәткәрләргә аттестацияләнергә тиешле вазыйфаи бурычларны үтәү турында, 1 нче кушымта нигезендә форма буенча төзелә торган, бәяләмә (алга таба-бәяләмә) һәм комиссиягә бирү зарурилыгы турында;

3) муниципаль хезмәт вазыйфалары категорияләрен һәм төркемнәрен, өлкәләрен һәм һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеген бәяләүнең кулланыла торган методлары турында;

4) муниципаль хезмәткәрне аттестация башланганчы ике атнадан да соңга калмыйча чакыртып алып таныштыру турында.

5) Комиссия эше өчен кирәкле материалларны әзерләү турында.

2.2. Аттестация үткәрү графигы аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе фикерен, алдагы аттестация үткәрү датасын исәпкә алып комиссия тарафыннан төзелә һәм ел саен район Башлыгы тарафыннан раслана.

Аттестация үткәрү графигы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә аттестация башланырга кимендә бер ай кала, аттестацияләнергә тиешле һәр муниципаль хезмәткәргә имзасын куйдырып, танышу өчен җибәрелә.

2.3. Аттестация үткәрү графигында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) аттестация үткәрелә торган җирле үзидарә органы, структур бүлекчә исеме;

б) аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәрләр исемлеге;

в) аттестация үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

г) Комиссиягә кирәкле документлар тапшыру датасы, аларны тапшыру өчен җаваплы җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре җитәкчеләре күрсәтеп.

2.4. Утырышны үз вакытында һәм сыйфатлы итеп оештыру максатыннан, Комиссиягә аттестация башланырга ике атнадан да соңга калмыйча, алдан, аттестация чоры өчен аттестация үтәргә тиешле муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын ничек үтәве турында, аның турыдан-туры һәм югарырак җитәкчесе тарафыннан имзаланган бәяләмә тапшырыла.

2.5. Бәяләмәдә муниципаль хезмәткәр турында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б) аттестация үткәрү вакытына муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы һәм шушы вазыйфага билгеләнү датасы;

в) муниципаль хезмәткәр аларны хәл итүдә (эшләүдә) катнашкан төп мәсьәләләр (документлар) исемлеге;

г) муниципаль хезмәткәрнең һөнәри, шәхси сыйфатларына һәм һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренә мотивлаштырылган бәя.

2.6. Аттестация чорында муниципаль хезмәткәрләргә аттестацияләнергә тиешле вазыйфаи бурычларны үтәү турындагы бәяләмәгә җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган йөкләмәләр һәм күрсәтелгән чор өчен муниципаль хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлеге турында еллык хисапларда күрсәтелгән документлар проектлары турында белешмәләр теркәлә.

Комиссиягә җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан һәр аттестация саен шулай ук муниципаль хезмәткәрнең алдагы аттестация күрсәткечләре белән аттестация кәгазе дә тапшырыла.

2.7. Аттестация үткәрү өчен Комиссия:

1) җирле үзидарә органнарына агымдагы елда муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү турында хәбәр итә;

2) һәр аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрне аттестация чорында үзләренең вазыйфаи бурычларын үтәү турында тәкъдим ителгән бәяләмә белән таныштыра. Шул ук вакытта аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәр күрсәтелгән чорда үз һөнәри эшчәнлеге турында өстәмә белешмәләр, шулай ук тәкъдимителгән бәяләмә белән килешмәү турында гариза яисә турыдан-туры җитәкченең бәяләмәсенә аңлатма язуы бирергә хокуклы.

3) бәяләү процедураларын оештыра;

4) Комиссия утырышын уздыру кысаларында оештыру-техник чараларны башкара;

4) билгеләнгән тәртиптә аттестация кәгазе (2 нче кушымта) һәм Комиссия карары рәсмиләштерә;

5) аттестация материалларын җирле үзидарә органнарына җибәрә.

2.8. Җирле үзидарә органнары җитәкчесе:

1) муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү турында хәбәр итә;

2) аттестация башланганчы ике атнадан да соңга калмыйча Комиссиягә аттестация чорында аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи бурычларын үтәү турында бәяләмә тапшыра;

3) муниципаль хезмәткәрләрне аттестация кәгазе белән таныштыруны тәэмин итә;

4) аттестация нәтиҗәләре буенча тиешле карар кабул итә;

5) аттестация материалларын муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси эшнамәсенә куя.

## Аттестацияне үткәрү

3.1. Аттестация аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрне Комиссия утырышына чакырып үткәрелә.

Муниципаль хезмәткәр аттестация үткәрү көнендә җитди сәбәпләр аркасында хезмәт урынында булмаса, аттестация үткәрү датасы соңрак вакытка күчерелә.

Җитди сәбәпләр булып түбәндәгедәр тора:

-аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәр яки аның гаилә әгъзаларының эшкә яраксызлык кәгазе белән расланган авыруы;

- аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрне командировкада булуы;

- Комиссия нигезле дип саный торган башка очраклар.

Муниципаль хезмәткәр әлеге комиссия утырышына җитди сәбәпсез килмәгән яисә аттестация үтүдән баш тарткан очракта, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартыла, ә аттестация соңрак вакытка күчерелә.

Аттестация үткәрү датасын, вакытын һәм урынын үзгәртү турында муниципаль хезмәткәр имза куйдырылып хәбәр ителергә тиеш.

Аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрне Комиссиясе утырышында җирле үзидарә органының тиешле структур бүлекчәсе җитәкчесе тәкъдим итә.

Комиссия тәкъдим ителгән документларны карый, аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрнең, ә кирәк булган очракта - аның турыдан-туры Җитәкчесенең муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге турында хәбәрләрен тыңлый. Аттестацияне объектив үткәрү максатларында Комиссия, аттестация чорында аттестация чорында аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрләргә тапшырылган өстәмә мәгълүматларны караганнан соң, аттестацияне комиссиянең киләсе утырышына күчерергә хокуклы.

3.2. Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлегенә карата һөнәри һәм шәхси сыйфатлары турында фикер алышу объектив һәм дустанә булырга тиеш.

Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлеге аның муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы буенча квалификация таләпләренә туры килүен билгеләү, аның тиешле бүлекчә (җирле үзидарә органы) алдында куелган бурычларны хәл итүдә катнашуы, алар башкара торган эшнең катлаулылыгы, аның нәтиҗәлелеге нигезендә бәяләнә.

Шул ук вакытта муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясен үтәү нәтиҗәләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри белемнәре һәм эш

тәҗрибәсе, муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләрне үтәве, тыюларны бозуы булмавы, муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән таләпләрнең һәм йөкләмәләрнең үтәлүе, шулай ук башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү вакытында, шулай ук оештыру сәләте исәпкә алынырга тиеш.

3.3. Аттестация нәтиҗәләре аттестацияләнгән муниципаль хезмәткәрләргә тавыш бирү нәтиҗәләрен чыгарганнан соң ук хәбәр ителә.

3.4. Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү материаллары җирле үзидарә органнарына аны үткәргәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

3.5. Аттестация уздырганнан соң бер ай эчендә, аның нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органының хокукый акты чыгарыла һәм җирле үзидарә органы җитәкчесенең муниципаль хезмәткәргә карата түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә һәм вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән тәртиптә кадрлар резервына кертүгә тәкъдим ителә;

б) өстәмә һөнәри белем алу өчен җибәрелә;

в) муниципаль хезмәт вазыйфасында түбәнәйтелә.

3.6. Муниципаль хезмәткәрнең квалификациясен күтәрүдән яисә муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчерүдән баш тарткан очракта, яллаучы (эш бирүче) муниципаль хезмәткәрне биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итәргә һәм аны муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә муниципаль хезмәттән азат итәргә хокуклы.

Аттестация уздырганнан соң бер ай узгач, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчерү йә аны муниципаль хезмәттән әлеге аттестация нәтиҗәләре буенча эштән азат итү рөхсәт ителми. Муниципаль хезмәткәрнең авырган чоры һәм еллык түләүле ялы вакыты күрсәтелгән вакытта исәпкә алынмый.

3.7. Муниципаль хезмәткәр аттестация нәтиҗәләренә гамәлдәге законнар нигезендә шикаять бирергә хокуклы

Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

Раслыйм:

______________________________
*(вазыйфсыа исемеи, ФИ.Ат.и.*

______________________________

______________________________
*(яллаучы вәкиле яки вәкаләтле зат имзасы);*

«___»____________20__ ел

**Аттестация чорында аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи бурычларын үтәү турында бәяләмә**

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме: ______________________________.

2. Аттестация уздыру вакытына муниципаль хезмәт вазыйфасы биләгән һәм әлеге вазыйфага билгеләнү датасы: ______________________________

______________________________________________________________.

3. Муниципаль хезмәткәр аларны хәл итүдә (эшләүдә) катнашкан төп мәсьәләләр (документлар) исемлеге:

______________________________________________________________

______________________________________________________________.

4. Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри, шәхси сыйфатларына һәм һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренә мотивлаштырылган бәя:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________.

______________________________ ______________ ______________
*(аттестацияләнүченең турыдан-туры җитәкчесе вазыйфасының атамасы)* *(имза)* *(имза аңлатмасы)*

«_____» ________________ 20___ел

Бәяләмә белән танышты:

______________________________________________________________
*(Муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.Ат.и., аның имзасы, танышу датасы)*

Зеленодольск муниципаль районының
җирле үзидарә органнарында муниципаль
хезмәткәрләрне аттестацияләү турындагы
нигезләмәгә
2 нче кушымта

Муниципаль хезмәткәрнең аттестация кәгазе

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ______________________________

______________________________

2. Туган елы, көне һәм ае ______________________________

______________________________

3. Һөнәри белеме, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме булу турында белешмәләр

______________________________

(кайчан һәм нинди уку йортын тәмамлаган,

______________________________

белгечлеге, әзерлек юнәлеше һәм белем буенча квалификациясе,

______________________________

гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме)

4. Аттестация вакытына муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы һәм бу вазыйфага билгеләнү датасы______________________________

______________________________

5 Муниципаль хезмәт стажы (шул исәптән дәүләт гражданлык хезмәте стажы)______________________________

6. Гомуми хезмәт стажы______________________________ 7.

Муниципаль хезмәткәргә сораулар һәм аларга кыска җаваплар ______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

8. Аттестация комиссиясе тарафыннан әйтелгән шелтә һәм тәкъдимнәр______________________________

______________________________

______________________________

9. Муниципаль хезмәткәрнең элекке аттестация тәкъдимнәрен үтәвен кыскача бәяләү______________________________

______________________________

(үтәлгән, өлешчә үтәлгән, үтәлмәгән)

10 Аттестация комиссиясе карары______________________________

(муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә,

______________________________

һәм вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен

______________________________

билгеләнгән тәртиптә кадрлар резервына кертүгә тәкъдим ителә;

______________________________

квалификацияне күтәрү шарты белән муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә;

______________________________

муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килми;)

______________________________

11. Аттестация комиссиясенең сан составы______________________________

Утырышта аттестация комиссиясенең ________ әгъзасы катнашты

________ риза, _________ каршы тавышлар саны.

12. Искәрмәләр ______________________________

______________________________

Аттестация комиссиясе
рәисе ______________________ ______________________________
(имза) (имза аңлатмасы)

Аттестация комиссиясе
рәисе урынбасары______________ ______________________________
(имза) (имза аңлатмасы)

Аттестация комиссиясе
секретаре ______________ ______________________________
(имза) (имза аңлатмасы)

Аттестация комиссиясе әгъзалары______________ ______________________________

(имза) (имза аңлатмасы)

______________ ____________________________________________________________

(имза) (имза аңлатмасы)

Аттестация үткәрү датасы______________________________________________

Аттестация кәгазе белән таныштты______________________________________

________________________________________________________________________

(муниципаль хезмәткәрнең имзасы, дата)

Мөһер урыны
(җирле үзидарә органнары,
муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе)